Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының тугызынчы утырышы

КАРАР

29 июнь, 2018 ел № 96

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карары хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставының 102, 103 ,104 статьялары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 15 июнендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга дигән әлеге карар.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Г.Х. Латыйпова

Питрәч авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
29 июнь, 2018 ел № 96

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 7 статьясындагы 1 өлешендә:

- 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, җирлек территориясен төзекләндерү, әлеге кагыйдәләргә туры китереп төзекләндерү;»;

- 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

2. «Җирлекнең җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә хокукы» 8 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

3. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 52 статьясында:

а) 1 өлешнең 7 пунктында:

- 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

- 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- төзекләндерү Кагыйдәләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру белән шөгыльләнә;»;

б) 2 өлешнең 12 абзацын үз көчен югалткан дип санарга;

(2018 елның 16 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 1 өлеш, әлеге кушымтаның 3 өлешендәге «а» пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә).